ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» июль 2019 ел. № 284

Татарстан Республикасы
Әгеҗе муниципаль районы Башкарма комитеты
опека һәм попечительлек органы секторының
аерым вәкаләтләрен тапшыру өчен
оешмаларны сайлап алу турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маеннан 423 номерлы карарын, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маеннан423 номерлы Карарын тормышка ашыру турында» 2009 елның 14 сентябреннән 334 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру буенча эш сыйфатын арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, балигъ булмаган гражданнарның опекуны яисә попечителе булырга теләк белдергән, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең башка гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвештә тәрбияләү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүче белем бирү оешмаларын, медицина оешмаларын, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларны сайлап алырга.
2. Оешмаларны сайлап алуны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторын билгеләргә.
3. Социаль хезмәтләр күрсәтүче белем бирү оешмаларын, медицина оешмаларын, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларны яки башка оешмаларны, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларны сайлап алу буенча комиссия составын төзеп расларга (1 нче Кушымта).
4. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторына оешмаларны сайлап алу барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында күсәтергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әгерҗе районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р.Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**

Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 12 июле № 284
санлы карарына кушымта

Социаль хезмәтләр күрсәтүче мәгариф оешмаларын, медицина оешмаларын, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларны сайлап алу комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. Гильмутдинова Римма Ринат кызы | - | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, **комиссия рәисе** |
| 2.Баһаутдинов Айсылу Гариф кызы | - | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы баш белгече, **комиссия рәисе урынбасары** |
| 3.Сутягина Альмира Рәсилевна | - | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы әйдәп баручы белгече, **комиссия сәркатибе** |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 4. Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы | - | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе башлыгы. |
| 5. Хайрутдинова Светлана Юрьевна | - | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре. |
| 6.Овчинникова Светлана Федот кызы | - | Әгерҗе район үзәк хастаханәсенең баш табиб урынбасары (килешү буенча). |
| 7. Шушакова Елена Николаевна | - | психологик-педагогик медик - социаль хезмәт җитәкчесе. |